КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 29 март г.Казань № 184

2025 – 2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның аерым категорияләрен медицина оешмаларына һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешенең 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2025 – 2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның аерым категорияләрен медицина оешмаларына һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

ведомство норматив хокукый актларын бу карарга туры китерергә;

Тәртипне куллану буенча аңлатмалар бирергә;

социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр һәм аларны алучылар турында, шулай ук ашыгыч социаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны Тәртип нигезендә Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыруны тәэмин итәргә. Әлеге мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру (аннан алу) «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

4. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 29 март, 184 нче карары белән расланды

## 2025 – 2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның аерым категорияләрен медицина оешмаларына һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

#### 1.1. Медицина оешмаларына һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүнең гомуми мәсьәләләре

1.1.1. Бу Тәртип 2025 – 2027 елларда «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын яхшырту программасын эшләү һәм тормышка ашыру» федераль проекты кысаларында сатып алынган автотранспорты булган Татарстан Республикасы муниципаль районнарында социаль хезмәтләр күрсәтүче Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләре (алга таба - халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре) тарафыннан авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны медицина оешмаларына һәм авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны һәм инвалидларны социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүне (алга таба шул ук эзлеклелектә – өлкән яшьтәге гражданнар, инвалидлар,вакытлы социаль хезмәтләр, медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү) җайга сала.

1.1.2. Медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәткәндә халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләр медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү кысаларында өлкән яшьтәге гражданнар алып барыла торган медицина оешмалары белән хезмәттәшлек итә.

1.1.3. Автотранспорт түбәндәгеләр белән җиһазланган булырга тиеш:

мөстәкыйль хәрәкәт итү сәләте чикле булган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны күчереп йөртү өчен кресло-коляска;

халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк турында (тулы исеме, адресы, элемтәгә керү өчен телефоннары, транспорт йөртүченең фотосурәте төшерелгән визит карточкасы), вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тотуны тәэмин итә торган орган турында (органның исеме, адресы һәм элемтәгә керү өчен телефоннары) белешмә бирелгән мәгълүмат тактасы (автотранспортның алгы панелендә урнаштырыла).

1.1.4. Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү өлкән яшьтәге граждан (инвалид) яши торган Татарстан Республикасы муниципаль районы чикләрендә халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Тукай муниципаль районында яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга вакытлы социаль хезмәтләр шулай ук «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округы территориясендә дә күрсәтелә.

1.1.5. Автотранспортны агымдагы карап тотуга норматив чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

1.1.6. Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү өчен социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын эшләү һәм алар белән социаль хезмәтләр күрсәтү турында килешү төзү таләп ителми.

### 1.2. Гражданнарга вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирүгә карата таләпләр

1.2.1. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләр, өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар алып барыла торган медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү оешмалары) тарафыннан өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга, аларның законлы вәкилләренә вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында ирекле формада түләүсез мәгълүмат бирү гамәлгә ашырыла.

1.2.2. Мәгълүмат бирү түбәндәге рәвештә гамәлгә ашырыла:

телефон элемтәсе аша;

рәсми сайтта, шулай ук халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкнең социаль челтәрләрдәге һәм мессенджерлардагы аккаунтларында мәгълүмат урнаштыру юлы белән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып;

халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк урыннарында, медицина оешмаларында һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында мәгълүмат стендларына мәгълүмат урнаштыру юлы белән;

массакүләм мәгълүмат чараларында публикацияләр, чыгышлар рәвешендә;

халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк бүлмәләрендә шәхси кабул итүдә булган өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга, аларның законлы вәкилләренә консультация бирү формасында;

һәркем файдалана алырлык башка ысуллар белән.

1.2.3. Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алу өчен шәхси мөрәҗәгать иткәндә халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк белгеченең кабул итү өчен максималь көтү срогы 15 минут тәшкил итә.

1.2.4. Вакытлы социаль хезмәт күрсәтүләр турында дөрес, вакытында яисә җитәрлек дәрәҗәдә тулы мәгълүмат бирелмәгәндә өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар, аларның законлы вәкилләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

1.2.5. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге һәм өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга күрсәтелә торган социаль хезмәтләр турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы карары нигезендә һәм «Социаль өлкәдә

бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы операторы билгеләгән форматлар нигезендә "Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасын куллану юлы белән алынырга мөмкин.

### 1.3. Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәткәндә куркынычсызлыгына карата таләпләр

1.3.1. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк түбәндәгеләрне тәэмин итә:

халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкнең транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерүне;

ел саен автотранспортка ясала торган техник тикшерү үткәрүне;

транспорт йөртүченең рейска чыгу алдыннан һәм рейстан кайтканнан соң медицина тикшерүен үткәрүне;

юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү өчен автотранспортны дарулар савыты белән тәэмин итүне.

1.3.2. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкнең вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтүне, аларның күрсәтелүен контрольдә тотуны гамәлгә ашыруны җайга сала торган документлары булырга тиеш.

Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк документларның актуальлеген, вакытында яңартып торылуын һәм искергән документларны әйләнештән алуны даими контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга тиеш.

1.3.3.Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк аның гамәлгә кую документларында билгеләнгән функцияләрне үтәгән, өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның хокукларын саклаган һәм ирекләрен яклаган өчен федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә җавап бирә.

1.3.4. Өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның, аларның законлы вәкилләренең вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтелә торган халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк хезмәткәрләренә билгеле булган шәхси характердагы мәгълүматның конфиденциальлегенә хокукы бар.

1.3.5. Шәхси характердагы мәгълүматны тараткан өчен өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар, аларның законлы вәкилләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

### 1.4. Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтүне кадрлар белән тәэмин итү дәрәҗәсенә карата таләпләр

1.4.1. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәктә вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле персонал саны булырга тиеш.

1.4.2. Тиешле квалификация белән беррәттән, халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк хезмәткәрләре тарафыннан өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның аларга ихтирамлы һәм гуманлы мөнәсәбәт булу хокукларын сакларга тиеш.

Автотранспорт йөртүчесенең «В» категорияле машина йөртү таныклыгы һәм кимендә ике ел машина йөртү стажы булырга тиеш.

1.4.3. Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәткәндә халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк хезмәткәрләре халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкнең гамәлгә кую документларында, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрендә каралган таләпләрне үтәргә, вазыйфаи инструкцияләр нигезендә үзләренә йөкләнгән функциональ бурычларын сыйфатлы башкарырга, һөнәри этиканы төгәл үтәргә тиеш.

1.5. Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү шартлары

Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү түләүсез нигездә башкарыла.

1.6. Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтүне туктату өчен нигезләр

Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга вакытлы социаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) өлкән яшьтәге гражданның (инвалидның) медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән яки социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән баш тартуы (язмача яки телдән). Өлкән яшьтәге граждан (инвалид) медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән яки социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән телдән баш тарткан очракта, халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк хезмәткәрләре тарафыннан тиешле акт төзелә;

2) өлкән яшьтәге граждан (инвалид) тарафыннан халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк директоры тарафыннан расланган вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтелгәндә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре үтәлмәү (бозылу);

3) өлкән яшьтәге гражданның (инвалидның) үлүе яисә халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкне ябу (эшчәнлеген туктату);

4) өлкән яшьтәге гражданны (инвалидны) иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүгә хөкем итү;

5) өлкән яшьтәге гражданның (инвалидның) вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдалануга комачаулый торган хәлдә сәламәтлеге начараю.

1.7. Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләү

Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләү вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын исәпкә алып гамәлгә ашырыла һәм вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү тулылыгын бәяләүне үз эченә ала (үз вакытында күрсәтү, шикаятьләр булмау, вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтүнең тулылыгын бәяләргә мөмкинлек бирә торган башка критерийлар).

1.8. Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтелә торган халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләр эшчәнлегенә карата таләпләр

1.8.1. Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәткәндә халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк түбәндәгеләргә бурычлы:

кеше һәм граждан хокукларын сакларга;

өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар шәхесенең кагылгысызлыгын һәм иминлеген тәэмин итәргә;

өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар турындагы мәгълүматны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән шәхси мәгълүматларны саклау турында таләпләр нигезендә кулланырга;

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга, аларның законлы вәкилләренә хокуклары һәм бурычлары турында, вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү сроклары, тәртибе һәм шартлары турында ирекле формада түләүсез мәгълүмат бирергә.

1.8.2. Вакытлы социаль хезмәтләр күрсәткәндә халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк түбәндәгеләргә хокуксыз:

өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләргә;

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга карата физик яки психологик көч кулланырга, аларны мыскыл итәргә, алар белән тупас мөгамәлә кылырга.

1.8.3. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк хезмәткәрләренең эш көне башлану, тәмамлану һәм көндезге ял вакыты халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкнең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән регламентлана.

1.8.4. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтүне эчке контрольдә тотуны;

2) медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү кысаларында өлкән яшьтәге гражданнар алып барыла торган медицина оешмалары белән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының уртак боерыгында билгеләнгән тәртиптә ведомствоара хезмәттәшлек итүне;

3) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләгән тәртиптә вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү документларын алып баруны;

4) вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтелгән өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләгән тәртиптә исәпкә алуны;

5) атна саен түбәндәгеләрне чагыштырып тикшерүне:

медицина оешмалары белән – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының уртак боерыгы белән расланган форма буенча чагыштырып тикшерү актын рәсмиләштереп, медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү кысаларында медицина оешмасына алып барылган өлкән яшьтәге гражданнар санын;

социаль хезмәт күрсәтү оешмалары белән – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының боерыгы белән расланган форма буенча чагышытырып тикшерү актын рәсмиләштереп, социаль хезмәт күрсәтү алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү кысаларында социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып барылган өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар санын;

6) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына вакытлы социаль хезмәтләр күрсәтү турында хисаплар тапшыруны.

## II. Медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү тәртибе

### 2.1. Медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәттән файдалану өчен мөрәҗәгать итү тәртибе

2.1.1. Медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү турындагы мәсьәләне карап тикшерү өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының уртак боерыгы белән расланган форма буенча дәвалау һәм диагностика чараларын үткәрүгә мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарның мәнфәгатьләрендә медицина оешмасының мөрәҗәгате (алга таба – медицина оешмасының мөрәҗәгате) нигез булып тора.

2.1.2. Медицина оешмасының мөрәҗәгате халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәккә курьер белән кәгазь чыганакта йә почта аша яки республика башкарма хакимият оганнарында идарә карарларын кабул итүгә ярдәм күрсәтүнең мәгълүмат-аналитика системасында ведомствоара мәгълүмат алышу кысаларында бирелә.

2.1.3. Медицина оешмасының мөрәҗәгатенә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының уртак боерыгы белән расланган форма буенча дәвалау һәм диагностика чараларын үткәрүгә мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарның исемлеге (алга таба – Исемлек) теркәлә.

Исемлектә өлкән яшьтәге гражданнарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), дәвалау һәм диагностика чараларын үткәрү өчен өлкән яшьтәге гражданнарны алып барырга кирәк булган медицина оешмасының исеме, адресы, дәвалау һәм диагностика чараларын үткәрү расписаниесе күрсәтелә.

Исемлек медицина оешмасы тарафыннан төзелә, дәвалау һәм диагностика чаралары үткәреләчәк медицина оешмасының баш табибы тарафыннан раслана.

Исемлеккә түбәндәге өлкән яшьтәге гражданнар кертелә:

«Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясында билгеләнгән таләпләрне үтәп, бу Тәртипнең 2.1.4 пунктында күрсәтелгән дәвалау һәм профилактика чараларын үткәрү өчен хәбәрдар булу турында үз теләге белән ризалык биргән;

дәвалау һәм диагностика чараларын үткәрү өчен медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булып торган һәм әлеге социаль хезмәтне күрсәткәндә медицина хезмәтләре белән тәэмин итүне таләп итми торган.

Исемлектә өлкән яшьтәге гражданнарның мөстәкыйль хәрәкәт итү сәләте чикле булу турында, шул исәптән кресло-коляскада йөрүе турында билге куела.

2.1.4. Бу Тәртип нигезендә медицина оешмаларына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтелә торган дәвалау һәм диагностика чаралары исемлеге:

диспансеризация һәм медицина профилактика тикшерүләре;

диспансеризация йомгаклары буенча өстәмә медицина тикшерүе;

диспансер күзәтүе;

скрининг тикшерүе;

вакцинация;

паллиатив медицина ярдәме күрсәтү;

планлы хастаханәгә салу;

авыру буенча мөрәҗәгать.

2.1.5. Исемлеккә түбәндәге авырулар белән авырган (хәлдә булган) өлкән яшьтәге гражданнар кертелмәскә тиеш:

деменция;

кискен авырулар яисә хроник авыруның кискенләшүе;

хроник авыруларның терминаль стадияләре;

медицина хезмәтләре белән тәэмин итүне яисә ашыгыч медицина ярдәменең күчмә бригадалары белән медицина оешмасына күчерүне, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүне таләп итә торган хәл.

### 2.2. Медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү тәртибе һәм өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) кабул ителгән карар турында хәбәр итү

2.2.1. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) медицина оешмасының мөрәҗәгатен кабул итүны һәм теркәүне;

2) Исемлекне өйрәнүне һәм «Татарстан Республикасы халкы социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру» ярдәмче системасында бирелгән белешмә нигезендә аңа кертелгән өлкән яшьтәге гражданнарга туры килү-килмәвенә тикшерүне;

3) медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итүне;

4) медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында медицина оешмасына хәбәр итүне.

Бу пунктның 1 – 3 пунктчаларында каралган эш итүләр халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк тарафыннан медицина оешмасына мөрәҗәгать кергән көннән ике эш көне эчендә башкарыла.

2.2.2. Өлкән яшьтәге гражданнарга медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча кәгазь чыганакта рәсмиләштерелә.

Өлкән яшьтәге гражданнарга медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында белешмә «Татарстан Республикасы халкы социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру» ярдәмче системасына электрон төрдә кертелә.

2.2.3. Өлкән яшьтәге гражданнарга медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында мәгълүмат, медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, медицина оешмасына язма рәвештә курьер белән йә почта аша яки республика башкарма хакимият органнарында идарә карарларын кабул итүгә ярдәм күрсәтүнең мәгълүмат-аналитика системасыннан җибәрелә.

Өлкән яшьтәге гражданнарга медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карарда баш тартуның сәбәбе күрсәтелә.

2.2.4. Медицина оешмасы язмача яисә телдән (телефоннан яки өйдә йә медицина оешмасында приемда булганда) өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка), бу Тәртипнең 2.2.3 пункты нигезендә мәгълүмат кергән көннән ике эш көне тәмамланганга кадәр, медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итә.P181

## 2.3. Медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр

Өлкән яшьтәге гражданнарга медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) медицина оешмасына дөрес булмаган белешмә бирү;

2) Исемлеккә кертелгән граждан өлкән яшьтәге гражданнар категориясенә керми;

3) Исемлектә күрсәтелгән медицина оешмасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк эшли торган Татарстан Республикасы муниципаль районыннан читтә урнашу (бу Тәртипнең 1.1.4 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш).

## 2.4. Медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү стандарты

2.4.1. Өлкән яшьтәге гражданнарга медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү максатларында халыкка социаль хезмәт күрсәтү

буенча комплекслы үзәк боерыгы белән аның хезмәткәрләре (машина йөртүче һәм социаль хезмәткәр (яисә социаль эш буенча белгеч яки шәфкать туташы)) арасыннан күчмә бригада (аның берничә составы булырга мөмкин) төзелә, аның эш тәртибе, әгъзаларының бурычлар бүленеше раслана.

2.4.2. Өлкән яшьтәге гражданнарга медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү турында карар кабул ителгән очракта, медицина оешмасының баш табибы белән килештереп, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге директоры тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының уртак боерыгы белән расланган форма буенча өлкән яшьтәге гражданнарны медицина оешмасына алып бару графигы (алга таба – Өлкән яшьтәге гражданнарны медицина оешмасына алып бару графигы) раслана һәм өлкән яшьтәге гражданнарга медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү турында карар кабул ителгән көннән ике эш көне үткәнгә кадәр медицина оешмасына җибәрелә.

Өлкән яшьтәге гражданнарны медицина оешмасына алып бару графигында өлкән яшьтәге граждан (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү адресы, хәрәкәтләнү сәләте турында белге), дәвалый һәм профилактика ясый торган медицина чараларын үткәрү планлаштырылган медицина оешмасы (исеме, адресы) турында белешмә, медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү датасы һәм вакыты турында мәгълүмат бирелә.

Өлкән яшьтәге гражданнарны медицина оешмасына алып бару графигы түбәндәгеләрне исәпкә алып төзелә:

дәвалау һәм диагностика чараларын үткәрү расписаниесе;

автотранспорт хәрәкәтенең оптималь маршруты.

Өлкән яшьтәге граждан (инвалид) медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән баш тарткан яисә аның сәламәтлеге медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән файдалана алмый торган хәлдә начарланган яки ул вафат булган очракта, әлеге вакыйгаларның берсе башланган көннән бер эш көне эчендә, медицина оешмасының баш табибы белән килештереп, халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк тарафыннан Өлкән яшьтәге гражданнарны медицина оешмасына алып бару графигына төзәтмәләр кертелә.

2.4.3. Өлкән яшьтәге гражданнарга медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү дигәндә өлкән яшьтәге гражданнарны үзләре яшәгән торак пунктның җыелу урыныннан медицина оешмасына кадәр алып бару һәм аннан алып кайту күздә тотыла.

Мөстәкыйль хәрәкәт итү сәләте чикле булган, шул исәптән кресло-коляскада йөрүче өлкән яшьтәге гражданнарны автотранспортка утырту һәм аннан төшерү үзләре яшәгән торак йорт янында гына башкарыла.

Өлкән яшьтәге гражданнарны транспорт белән алып бару социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкнең социаль хезмәткәре (яисә социаль эш буенча белгеч яки шәфкать туташы) ярдәме белән гамәлгә ашырыла.

2.4.4. Медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәткәндә халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк хезмәткәрләренең эш итү тәртибе:

1) өлкән яшьтәге гражданнарга, кресло-коляскада йөрүчеләргә өс киемен киюдә, өйдән чыгуда, җыелу урынына кадәр баруда, ә медицина оешмасыннан кайтканда өйгә кадәр кайтып җитүдә, өс киемен салуда ярдәм күрсәтү;

2) җыелу урынында өлкән яшьтәге гражданнарны транспортка утыртуны һәм куркынычсыз урында төшерүне тәэмин итү, түбәндәгеләрне кертеп:

автотранспортка утырганда һәм аннан төшкәндә өлкән яшьтәге гражданнарга, шул исәптән кресло-коляскада йөрүчеләргә ярдәм күрсәтүне;

өлкән яшьтәге гражданнарга куркынычсызлык каешларын эләктерүне;

автотранспортта кресло-колясканы эләктереп куюны;

3) медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтелә торган көнне өлкән яшьтәге граждан белән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча төзелгән медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү актына кул кую.

2.4.5. Медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдә катнашу кысаларында медицина оешмасы хезмәткәрләренең эш итү тәртибе:

1) өлкән яшьтәге гражданга киләсе дәвалау һәм профилактика чараларын үткәрү һәм медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү датасы, вакыты турында беренче тапкыр мәгълүмат бирү халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәктән Өлкән яшьтәге гражданнарны медицина оешмасына алып бару графигы алынган көннән ике эш көне үткәнгә кадәр гамәлгә ашырыла (өендә булганда яки медицина оешмасында приемда булганда яисә телефоннан)

2) өлкән яшьтәге гражданнарга кабат мәгълүмат бирү, шул исәптән:

киләсе дәвалау һәм профилактика чараларын үткәрү датасы турында;

медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү өчен өлкән яшьтәге гражданнар яши торган авыл торак пунктында аларны җыю вакыты һәм урыны турында;

киләсе дәвалау һәм профилактика чараларына әзерләнү кагыйдәләре турында;

өлкән яшьтәге граждан үзе белән медицина оешмасына алырга тиешле документлар исемлеге турында.

Мәгълүмат дәвалау һәм профилактика чараларын үткәрү һәм медицина оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү көненә кадәрге көн алдыннан (өйдә булганда яисә телефон аша) кабат хәбәр ителә;

3) дәвалау һәм профилактика чараларын үткәрү чорында өлкән яшьтәге гражданнарга медицина оешмасында ярдәм итүне тәэмин итү;

4) атна саен өлкән яшьтәге гражданнарга беренче медицина-санитария ярдәме күрсәтү һәм медицина тикшерүен үткәрү турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына bars.tatar.ru программа чарасы аша хисап бирү.

## III. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү тәртибе

### 3.1. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтелү өчен мөрәҗәгать итү тәртибе

3.1.1. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү турындагы мәсьәләне карап тикшерү өчен социаль хезмәт күрсәтү оешмасының көндезге бүлегендә (төркемендә) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтелүче өлкән яшьтәге гражданның (инвалидның) яисә аның законлы вәкиленең өлкән яшьтәге граждан яши торган Татарстан Республикасы муниципаль районындагы социаль хезмәтләр күрсәтелә торган халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәктә тапшырылган социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү турында гаризасы (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү турында гариза) нигез булып тора.

3.1.2. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү турында гариза Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза формасын раслау хакында» 2014 елның 28 мартындагы 159н номерлы боерыгы белән расланган формада, кәгазь чыганакта курьер аша тапшырыла яисә почта аша җибәрелә яки лкән яшьтәге гражданга (инвалидка) көндезге бүлектә (төркемдә) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмасы тарафыннан тапшырыла.

### 3.2. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү һәм өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) кабул ителгән карар турында хәбәр итү тәртибе

3.2.1. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул иткәндә халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкнең эш итү тәртибе:

1) социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү күрсәтү турында гариза кабул итү һәм теркәү;

2) социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән белешмәне өйрәнү һәм тикшерү, гражданнарның өлкән яшьтәге гражданнар (инвалидлар) категориясенә туры килү-килмәвен билгеләү;

3) социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

4) өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) йә аның законлы вәкиленә кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

Бу пунктның 1 – 3 пунктларында каралган гамәлләр халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү оешмасына

алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән көнне башкарыла.

3.2.2. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча кәгазь чыганакта рәсмиләштерелә.

Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында белешмә «Татарстан Республикасы халкы социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру» ярдәмче системасына электрон төрдә кертелә.

3.2.3. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәрнамә мондый карар кабул ителгән көннән ике эш көне эчендә өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) яисә аның законлы вәкиленә җибәрелә.

Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карарда баш тартуның сәбәбе күрсәтелә.

### 3.3. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр

Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) өлкән яшьтәге граждан  (инвалид) тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр бирелү;

2) граждан «өлкән яшьтәге граждан» яисә «инвалид» категориясенә керми;

3) өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) көндезге бүлектә (төркемдә) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмасы социаль хезмәтләр күрсәтелә торган халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплексլы үзәк урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль районыннан читтә булу (бу Тәртипнең 1.1.4 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш).

### 3.4. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү стандарты

3.4.1. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү максатларында халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк боерыгы белән аның хезмәткәрләре (машина йөртүче һәм социаль хезмәткәр (яисә социаль эш буенча белгеч)) арасыннан күчмә бригада (аның берничә составы булырга мөмкин) төзелә, аның эш тәртибе, әгъзаларының бурычлар бүленеше раслана.

3.4.2. Өлкән яшьтәге граждан (инвалид), социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү турында вакытлы социаль хезмәт

күрсәтү турында карар кабул ителгән очракта, өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмасына өлкән яшьтәге гражданны (инвалидны) алып бару графигына (алга таба – Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару графигы) кертелә.

Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару графигы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган форма буенча төзелә һәм анда граждан турында (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү адресы, хәрәкәт итүгә сәләте турында билге), өлкән яшьтәге граждан (инвалид) алып барыла торган, өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмасы турында (исеме, адресы) белешмә, социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү датасы һәм вакыты турында мәгълүмат бирелә.

Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару графигы түбәндәгеләрне исәпкә алып төзелә:

социаль хезмәт күрсәтү оешмасының көндезге бүлегендә (төркемендә) социаль хезмәтләр күрсәтү расписаниесе;

автотранспортның оптималь маршруты.

3.4.3. Өлкән яшьтәге граждан (инвалид) социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән баш тарткан яисә аның сәламәтлеге социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтүдән файдалана алмый торган хәлдә начарланган яки ул вафат булган очракта, әлеге вакыйгаларның берсе булган көннән бер эш көне эчендә халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк тарафыннан Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару графигына төзәтмәләр кертелә.

3.4.4. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү дигәндә өлкән яшьтәге гражданны (инвалидны) транспорт белән үзе яшәгән торак йорттан социаль хезмәт күрсәтү оешмасына кадәр алып бару һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмасының көндезге бүлегендә (төркемендә) социаль хезмәтләр күрсәтү тәмамланганнан соң кире алып кайту күздә тотыла.

3.4.5. Өлкән яшьтәге гражданнарны (инвалидларны) транспорт белән алып бару халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкнең социаль хезмәткәре (яисә социаль эш буенча белгече) ярдәме белән гамәлгә ашырыла.

3.4.6. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү датасы, вакыты, халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкнең аны оештыру өчен җаваплы хезмәткәренең, шулай ук күчмә бригада әгъзаларының элемтәгә керү өчен телефоннары турында мәгълүмат бирелә.

Мәгълүмат өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга яисә аларның законлы вәкилләренә халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк

хезмәткәре тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару көненә кадәрге көн алдыннан телефон элемтәсе аша йә социаль хезмәт күрсәтү оешмасында социаль хезмәтләр күрсәтелгәндә телдән хәбәр ителә;

2) өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны куркынычсыз урында транспортка утыртуны һәм аннан төшерүне тәэмин итү, шул исәптән түбәндәгеләрне кертеп:

автотранспортка утырганда һәм аннан төшкәндә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга, шул исәптән кроесло-коляска белән хәрәкәт итүчеләргә ярдәм күрсәтүне;

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга куркынычсызлык каешларын эләктерүне;

автотранспортта кресло-колясканы эләктереп куюны;

3) социаль хезмәт күрсәтү оешмасына кадәр алып барганда һәм аннан алып кайтканда өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга булышлык күрсәтеп тору;

4) социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтелә торган көнне өлкән яшьтәге граждан (инвалид) яисә аның законлы вәкиле белән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча төзелгән социаль хезмәт күрсәтү оешмасына алып бару буенча вакытлы социаль хезмәт күрсәтү актына кул кую.